ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
(IV чакырылыш)
КАРАР
кырык бишенче утырыш

01 ноябрь 2024 ел **№ 174** **Шәтке авылы**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 нче ноябрендәге 142 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр керту хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2024 елның 12 июлендәге 05-11/4815 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 нче ноябрендәге 142 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 2 пунктчасында “, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата” сүзләрен төшереп калдырырга;

– түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктча белән тулыландырырга

"2.1) салым салу объектларына карата 2,5 процент, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә;";

- 2 пунктны түбәндәге редакциядәге 4 пунктча белән тулыландырырга:

«4) 2025-2027 еллар чорына 1000 квадрат метрдан артык гомуми мәйдандагы сәүдә һәм административ-эшлекле үзәкләргә (комплексларга) карата һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән биналарга карата 1,2 процент.»;

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Шәтке авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Кадыйров

СОВЕТ ШАДКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ